**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

29 май 2019 ел № 228

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советынын 2016 елның 15 ноябрендәге 82нче номерлы «Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында.

Бишнә авыл җирлеге башлыгы И. М. Фәтхуллинның Бишнә авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 82 номерлы «Яшел Үзән муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге территориясендә торак төзелешенең социаль әһәмиятен исәпкә алып, җир салымын түләү тәртибе һәм сроклары турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Бишнә авыл җирлеге Советы Бишнә авыл җирлегендә торак төзелешенең социаль әһәмиятен исәпкә алып, Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Бишнә авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 82 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 нче пунктны киләсе эчтәлекле 1.12.1 пунктчасы белән тулыландырырга.:

«1.12.1) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»гы 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган махсуслаштырылган оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата салым ставкасын 0,001% ка кадәр киметү.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен бирә.

3. Әлеге карарны «Яшел Узэн» газетасында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе: И.М.Фатхуллин**